**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«31» октябрь 2019 ел №8/2

«Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 26 сентябрендәге «Җир салымы турында» 23/5 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 75 пункты, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 26 сентябрендәге «Җир салымы турында» 23/5 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Җир салымы турында» карарның 2 өлешендә өченче һәм бишенче абзацларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,3% (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына кермәгән объектка туры килә торган яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш);»;

«5) торак фонд биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,2% (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына кермәгән объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш).».

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнвареннән үз көченә керә, ләкин мәгълүмат стендларында һәм районның рәсми сайтында урнаштырылган көннән соң бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Иске Дөреш авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
Совет рәисе Р.М. Дусадбеков